**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЮТАЗЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР №28**

**Ютазы ав.** **«26» декабря 2024 ел**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ютазы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы 25-ФЗ санлы Федераль закон, 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы көрәш турында»гы 273-ФЗ санлы Федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2013 елның 23 июнендәге «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» турындагы 50-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ютазы авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ютазы авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Советының 2023 елның 1 мартындагы 5 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ютазы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә (алга таба — нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 8.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенең гомуми принципларын үтәвен һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салуны тәэмин итү өчен җирле үзидарә органында Россия Федерациясе субъектының норматив хокукый актларында һәм муниципаль хокукый актта билгеләнгән тәртиптә муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтларын җайга салу буенча комиссияләр төзелергә мөмкин.

Комиссия даими булмаган нигездә җирле үзидарә органының хокукый акты белән төзелә.

Күрсәтелгән акт белән комиссиянең санлы һәм персональ составы, аның эш вакытлары һәм тәртибе билгеләнә.

Комиссия составына яллаучының (эш бирүченең) вәкиле һәм (яисә) ул вәкаләт биргән муниципаль хезмәткәрләр, шулай ук муниципаль хезмәткә бәйле мәсьәләләр буенча белгечләрнең бәйсез экспертлары сыйфатында шәхси белешмәләрне күрсәтмичә чакырыла торган фәнни һәм мәгариф һәм (яисә) башка оешмаларның вәкиле кертелә. Бәйсез экспертлар саны комиссия әгъзаларының гомуми санынннан кимендә дүрттән берен тәшкил итәргә тиеш. Комиссия составы комиссия кабул иткән карарларга йогынты ясый алырлык мәнфәгатьләр конфликтлары килеп чыгу мөмкинлеген булдырмаслык итеп формалаштырыла.»;

1.2. Нигезләмәнең 6.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Җирле үзидарә органы җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары, мәнфәгатьләр конфликтын бетерү максатларында, алар тиешле вазыйфаны биләгән чорда әлеге җирле үзидарә органының сайланулы профсоюз органында муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен яклый алмый.»;

1.3. Нигезләмәнең 2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Муниципаль хезмәт вазыйфасы - җирле үзидарә органының яисә муниципаль вазыйфаны биләүче затның вәкаләтләрен үтәүне тәэмин итү буенча билгеләнгән бурычлар даирәсе булган муниципаль берәмлек уставы нигезендә төзелә торган җирле үзидарә органындагы вазыйфа.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Ютазы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге торак пунктлары территориясендәге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (https://pravo.tatarstan.ru Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан 2013 елның 17 декабрендә бирелгән ЭЛ ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ электрон адресы буенча дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы «Рәсми Татарстан» ны урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Ютазы авыл җирлеге башлыгы — Л.М.Хәйруллина